# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмә кертү хакында**

**1 статья.** «Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында» 1994 елның 19 июлендәге 2180-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәне кертергә:

1. Преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Закон чит ил инвестицияләрен җәлеп итүгә һәм аларны Татарстан Республикасы икътисадында нәтиҗәле файдалануга юнәлтелгән».

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә чит ил инвесторларының Татарстан Республикасы карамагына керүче мәсьәләләр буенча эшкуарлык эшчәнлегенең төп хокукый, икътисадый һәм социаль шартларын билгели.».

2. 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Чит ил инвестицияләренә бәйле мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Чит ил инвестицияләренә бәйле мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу федераль законнар, әлеге Закон һәм бүтән норматив хокукый актлар белән башкарыла.».

3. 2 статьяда:

беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чит ил инвестициясе - эшкуарлык эшчәнлеге объектына чит ил инвесторының граждан хокуклары объектлары рәвешендә (әгәр граждан хокукларының андый объектлары федераль законнар нигезендә Россия Федерациясендә әйләнештән алынмаган яисә аларның әйләнеше чикләнмәгән булса) чит ил капиталы кертү, шул исәптән акча, кыйммәтле кәгазьләр (чит ил валютасында һәм Россия Федерациясе валютасында), интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә (интеллектуаль милеккә) махсус

хокукларның акчалата бәясенә ия бүтән мөлкәт, мөлкәти хокуклар, шулай ук хезмәт күрсәтүләр һәм мәгълүмат кертү.»;

икенче өлешне төшереп калдырырга;

бишенче өлештә «Татарстан Республикасы законы» сүзләрен «законнар» сүзенә алмаштырырга.

4. 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 статья. **Чит ил инвесторлары**

Түбәндәгеләр чит ил инвесторлары була ала:

- граждани хокукый сәләтләре үзләре гамәлгә куелган дәүләтнең законнары нигезендә билгеләнә торган һәм күрсәтелгән дәүләтнең законнары нигезендә Россия Федерациясе территориясендә инвестицияләрне гамәлгә ашырырга хокуклы чит ил юридик затлары;
- граждани хокукый сәләтләре үзләре гамәлгә куелган дәүләтнең законнары нигезендә билгеләнә торган һәм күрсәтелгән дәүләтнең законнары нигезендә Россия Федерациясе территориясендә инвестицияләрне гамәлгә ашырырга хокуклы юридик зат булмаган чит ил оешмалары;
- граждани хокукый сәләтләре һәм хокуктан файдалану сәләтләре үзләренә гражданлык биргән дәүләтнең законнары нигезендә билгеләнә торган һәм күрсәтелгән дәүләтнең законнары нигезендә Россия Федерациясе территориясендә инвестицияләрне гамәлгә ашырырга хокуклы чит ил гражданнары;
- даими рәвештә Россия Федерациясе чикләреннән читтә яшәүче, граждани хокукый сәләтләре һәм хокуктан файдалану сәләтләре үзләре даими яшәүче дәүләтнең законнары нигезендә билгеләнә торган һәм күрсәтелгән дәүләтнең законнары нигезендә Россия Федерациясе территориясендә инвестицияләрне гамәлгә ашырырга хокуклы гражданлыксыз затлар;
- Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә Россия Федерациясе территориясендә инвестицияләрне гамәлгә ашырырга хокуклы халыкара оешмалар һәм фондлар;
- федераль законнарда билгеләнә торган тәртип нигезендә чит дәүләтләр.».

5. 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Чит ил инвестицияләре объектлары**

Республика икътисадының барлык тармакларындагы һәм өлкәләрендәге яңа төзелгән, модернизацияләнгән һәм гамәлдә булган төп фондлар, әйләнеш чаралары, кыйммәтле кәгазьләр, акчалата максатчыл кертемнәр, фәнни-техник продукция, интеллектуаль кыйммәтләргә хокуклар, җир, башка табигый байлыклар, бүтән мөлкәти хокуклар чит ил инвестицияләренең объектлары була алалар.

Конституциячел корылыш нигезләрен, әхлаклылыкны, башка затларның сәламәтлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, илнең оборонасын һәм дәүләтнең иминлеген тәэмин итү максатында чит ил инвесторларына федераль законнар белән чикләүләр билгеләнә.».

6. I бүлеккә түбәндәге эчтәлектә 5[1] статья өстәргә:

«5[1] статья. **Чит ил инвестицияләре белән коммерциячел оешмалар төзү һәм аларны бетерү**

Чит ил инвестицияләре белән коммерциячел оешмалар төзү һәм аларны бетерү Россия Федерациясенең Граждан кодексында һәм бүтән федераль законнарда каралган шартларда һәм тәртиптә башкарыла.

Чит ил инвестицияләре белән коммерциячел оешмалар юстиция органнарында федераль законнар нигезендә дәүләт теркәве узарга тиешләр.».

7. 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья. **Чит ил инвесторларын хокукый яклау гарантиясе**

Татарстан Республикасы территориясендә чит ил инвесторының хокуклары һәм мәнфәгатьләре тулысынча һәм һичшиксез хокукый яклана, ул Россия Федерациясе законнары, халыкара шартнамәләр, әлеге Закон белән тәэмин ителә.».

8. 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Чит ил инвесторының яисә чит ил инвестицияләре булган коммерциячел оешманың мөлкәтен национализацияләгәндә һәм реквизицияләгәндә компенсацияләү гарантиясе**

Татарстан Республикасында инвесторның яисә чит ил инвестицияләре булган коммерциячел оешманың мөлкәте, федераль закон яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе белән билгеләнгән очраклардан һәм нигезләрдән тыш, мәҗбүри тартып алынмый, шул исәптән национализацияләнми, реквизицияләнми.

Мөлкәтне реквизицияләү һәм национализацияләү Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә башкарыла.».

9. 9, 10, 12 статьяларның исемнәрендә «гарантияләр» сүзен «гарантия» сүзенә алмаштырырга.

10. 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Татарстан Республикасы законнарын зыянлы үзгәртүдән гарантия**

Чит ил инвесторларының һәм чит ил инвестицияләре булган коммерциячел оешмаларның эшчәнлеге шартларын начарайта торган яңа Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары үз көченә кергән очракта, инвестиция проектының үзен аклау чорына, әмма җиде елдан да артыкка түгел, инвесторларның эшчәнлек шартларын начарайтучы норматив хокукый актлар кабул ителү мизгеленә гамәлдә булган инвестиция шартнамәсе яисә бүтән шартнамә (килешү, контракт) һәм законнар белән билгеләнгән шартлар алар өчен гамәлдә калалар.».

11. 3 бүлекне төшереп калдырыга.

12. 40 статьяда «законнары» сүзе алдындагы «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга һәм «законнары» сүзен «законнар» дип язарга.

13. 41 статьяның беренче өлешендә «рубльләргә дә, чит ил валютасына да» сүзләрен төшереп калдырырга.

14. 42 статьяның беренче өлешендә «һәм коммуналь» сүзләрен төшереп калдырырга.

15. 44 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«44 статья. **Бәхәсләрне хәл итү тәртибе**

Чит ил инвесторларының һәм чит ил инвестицияләре булган предприятиеләрнең инвестицияләрне һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле килеп чыга торган бәхәсләре законнар нигезендә хәл ителә.».

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 27 июне
№ 901